Әлмәт шәһәре Башлыгы
карары

28 апрель 2020 ел № 13

Гавами тыңлауларны билгеләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Әлмәт муниципаль районының Әлмәт шәһәрендә гавами тыңлаулар уздыру турындагы нигезләмәгә таянып,

КАРАР БИРӘМ:

1. Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Әлмәт муниципаль районы, Әлмәт шәһәр җирлеге, Әлмәт шәһәре, Ленин урамы, 171 й. адресы буенча урнашкан күпфатирлы торак йорт территориясен ызанлау проекты турында фикер алышу буенча гавами тыңлаулар билгеләргә.
2. Гавами тыңлаулар уздыру вакыты - әлеге карар басылып чыккан көннән алып кимендә бер айдан да ким һәм өч айдан да артык булмаган вакытка.
3. Гавами тыңлауларда катнашучыларның җыелышын Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Әлмәт муниципаль районы, Әлмәт шәһәре шәһәр җирлеге, Әлмәт шәһәре, Ленин ур., 39 й. адресы буенча Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының зур утырышлар залында 2020 елның 22 маенда 15.15 сәгатьтә уздырырга.
4. Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Әлмәт муниципаль районы, Әлмәт шәһәре шәһәр җирлеге, Әлмәт шәһәре, Габдулла Тукай проспекты, 9А йорт, 3 каб. адресы буенча урнашкан "Әлмәт муниципаль районының архитектура һәм шәһәр төзелеше идарәсе" муниципаль бюджет учреждениесендә территорияне ызанлау проекты буенча тәкъдимнәр һәм кисәтүләр кабул ителә яисә uag_arhitektura@mail.ru. электрон адреска юллана.
5. «Әлмәт муниципаль районының архитектура һәм шәһәр төзелеше идарәсе» муниципаль бюджет учреждениесенә (Мордагулова Р.Р.) беркетмә үткәрү, әзерләү һәм гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә бирүне оештырырга.
6. Район Башкарма комитетының Хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.
7. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.
8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны башкарма комитеты җитәкчесенең төзелеш буенча урынбасары Д. В. Косаревка йөкләргә.

Шәһәр Башлыгы Т.Д. Нагуманов